РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 26 » 01 2023 ел №63

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 27 июнендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында»гы 977 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясенең Гражданлык кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хуҗаларының тормыш шартларына, хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кеше хокукларын үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 27 июнендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында»гы 977 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын эшләү турында»;

1.2. Карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын эшләүгә керешергә.».

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2023 елның 27 июненнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина